ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.11.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**2597**

«Зеленодольск муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының фасадларын һәм территорияләрен, социаль-мәдәни өлкәсе объектларының иң яхшы яңа ел бизәлеше» муниципаль конкурсын уздыру турында нигезләмәне раслау хакында

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының фасадларын һәм территорияләрен, социаль-мәдәни өлкә объектларын эстетик бизәүне яхшырту максатларында Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Зеленодольск муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының фасадларын һәм территорияләрен, социаль-мәдәни өлкәсе объектларының иң яхшы яңа ел бизәлеше» муниципаль конкурсын уздыру турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. «Зеленодольск муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының фасадларын һәм территорияләрен, социаль-мәдәни өлкәсе объектларын яңа ел бизәлеше буенча конкурс оештыру һәм үткәрү комиссиясе составын раслау (2 нче кушымта).
3. «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ конкурсларның приз фондына күрсәтелгән максатларга финанслауны Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган акчалар исәбеннән. 275 000 сум күләмендә тормышка ашырырга. (3 нче кушымта).
4. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына шәһәр массакүләм мәгълүмат чараларында, Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында конкурс уздыру турында мәгълүматны урнаштыруны тәкъдим итәргә.
5. Конкурска 27.12.2019 кадәр йомгак ясарга. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләүне. 2019 елның 31 декабрендә 18.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр "Авангард" мәдәният-спорт комплексында үткәрергә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин